ГЛАВА ШЕЛАНГОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ШИЛАНГЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　КАРАР

08.11.2021　　　　с. Шеланга　　　　09

«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлеге Нариман авылында гражданнар җыенын билгеләү турында» Шилангы авыл җирлеге башлыгы карарын юкка чыгару хакында

Яңа коронавирус йогышының алга таба таралуына юл куймау максатларында, "Татарстан Республикасында яңа коронавирус инфекциясе таралуны булдырмау чаралары турында" 2020 елның 19 мартындагы 208 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021нче елның 28нче октябреннән 1006 номерлы карарына таянып,

Карар бирәм:

1. "Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлеге Нариман авылында гражданнарның үзара салым акчаларын куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү һәм үткәрү турында» Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлеге башлыгының 2021 елның 29нчы октябреннән 7нче номерлы карарын гамәлдән чыгарырга
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Шилангы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Югары Ослан муниципаль районы
Шилангы авыл җирлеге башлыгы　　　　　　　　В.В.Майоров